СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**

**КАРАРЫ**

**2019 ел «20» август** **№ 266**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм (яки) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләү яисә файдалану өчен билгеләнгән, өченче затлар хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән муниципаль мөлкәтне, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибен һәм Исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәтне формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару Тәртибен раслау турында**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга мөлкәт ярдәме күрсәтү максатларында, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясына таянып, Арча муниципаль район Советы КАРАР бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм (яки) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләү яисә файдалану өчен билгеләнгән, өченче затлар хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән муниципаль мөлкәтне, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм (яки) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләү яисә файдалану өчен билгеләнгән, өченче затлар хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) муниципаль мөлкәтне, шул исәптән җир кишәрлекләре (шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) Исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару Тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

3.Әлеге карар Татарстан Республикасы "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә

5. Әлеге карарның үтәлешен Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе И.И.Игнатовка йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе — И.Г. Нуриев

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы Советының 2019 елның
_____ ___________________________________
____ номерлы карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм (яки) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләү яисә файдалану өчен билгеләнгән, өченче затлар хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән муниципаль мөлкәтне, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм (яки) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләү яисә файдалану өчен билгеләнгән, өченче затлар хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән муниципаль мөлкәтне, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибе (алга таба - Тәртип) Россия Федерациясенең Гражданнар кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2007 елның 24 июлендәге "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 209-ФЗ номерлы Федераль закон, 2006 елның 26 июлендәге "Конкуренцияне яклау турында" 135-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары һәм Арча муниципаль районының муниципаль хокукый актлары нигезендә эшләнде.

1.2.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль берәмлеге исемлеккә кертелгән мөлкәтнең милекчесе булып тора.

1.3.Исемлекне формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару тәртибе Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советы карары белән билгеләнә.

1.4.Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм (яки) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләү яисә файдалану өчен билгеләнгән, өченче затлар хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) муниципаль мөлкәт Исемлегенә (алга таба – Исемлек) кертелгән муниципаль мөлкәтне, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) бирү процедурасын һәм мөлкәтне кече һәм урта эшкуарлык субъектларына аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча бирү шартларын билгели.

1.5.Муниципаль милекне арендага бирүче булып Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәт милекчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру вәкаләте булган орган тора.

1.6.Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалаучы булып 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ярдәм күрсәтелә алмый торган кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан тыш булган

авыл хуҗалыгы кооперативлары яки социаль әһәмиятле эшчәнлек төрләре белән яки эшчәнлекнең өстенлекле муниципаль программалары (ярдәмче программалары) буенча шөгыльләнүче кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тора.

1.7. Эшчәнлекнең өстенлекле төрләрен күздә тота торган социаль әһәмияткә ия муниципаль программалар (ярдәмче программалар) булмаган очракта, Арча муниципаль районы территориясендә эшчәнлекнең өстенлекле төрләре Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

## 2. Муниципаль милекне арендага бирү

2.1. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәләрен төзү исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәләрен төзү хокукына аукцион формасында үткәрелгән ачык сатулар нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла (алга таба – сатулар).

2.2.Арендага бирүче сатулар оештыру һәм үткәрү функцияләрен башкара.

2.3.Сатулар үткәрү, сатулар үткәрү нәтиҗәләре буенча исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау килешүләре төзү гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

2.4.Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатуларда катнашуга гаризалар бирү, гаризага кушып бирелә торган документларга карата таләпләр, сатуларда катнашуга рөхсәт бирмәү өчен нигезләр аукцион турында документлар белән билгеләнә.

2.5.Исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәтне арендалаучы, субаренда шартнамәсе буенча, өченче затларга муниципаль мөлкәтнең гомуми арендалана торган мәйданыннан 30 процентка кадәренә үз хокукларын һәм бурычларын тапшырырга хокуклы.

2.6.Арендалаучы муниципаль мөлкәтне 2007 елның 24 июлендәге "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 209-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тыюларны үтәп, максатчан файдаланырга тиеш.

2.7. Исемлеккә кертелгән мөлкәткә карата шартнамәләр төзелә торган вакыт кимендә биш ел тәшкил итәргә тиеш. Килешү вакыты мондый шартнамә төзелгәнче ия булу һәм (яки) файдалану хокукларын алучы затның бирелгән гаризасы нигезендә киметелергә мөмкин.

## 3.Аренда түләве һәм аны кертү тәртибе

3.1.Исемлеккә кертелгән муниципаль милек өчен аренда түләве күләме мөлкәтне арендалау шартнамәләре өчен сатулар үткәрү нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

3.2.Аренда шартнамәсенең башлангыч бәясе Россия Федерациясе бәяләү эшчәнлеге турындагы закон нигезендә әзерләнгән аренда түләвенең базар бәясен бәяләү турындагы хисап нигезендә билгеләнә.

3.3.Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәсен төзегәндә биш елга аренда түләве арендалаучы тарафыннан:

– аренданың беренче елында- аренда килешүендә билгеләнгән аренда түләве күләменнән 0 процент тәшкил итә;

– аренданың икенче елында- аренда килешүендә билгеләнгән аренда түләве күләменең 0 проценты;

– аренданың өченче елында-аренда килешүендә билгеләнгән аренда түләве күләменең 25 процентын;

– аренданың дүртенче елында- аренда килешүендә билгеләнгән аренда түләве күләменең 50 процентын тәшкил итә;

– аренданың бишенче елында- аренда килешүендә билгеләнгән аренда түләве күләменең 75 процентын тәшкил итә.

3.4.Исемлеккә кертелгән мөлкәтне яңа срокка арендалау шартнамәсен төзегәндә арендалаучы тарафыннан 100 процент күләмендә аренда түләве кертелә.

3.5.Килешүне вакытыннан алда өзгән очракта арендалаучыга мөлкәттән файдалануның бөтен вакытын,сатулар үткәрү нәтиҗәләре буенча билгеләнгән базар бәясеннән чыгып, тулы күләмдә түләргә кирәк.

3.6.Муниципаль милектән файдаланган өчен аренда түләве Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетына күчерелә.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль район Советының 2019 елның
____ ____________________________
_____номерлы карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм (яки) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләү яисә файдалану өчен билгеләнгән, өченче затлар хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) муниципаль мөлкәтне, шул исәптән җир кишәрлекләре (шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) Исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару Тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

**1.1.** Әлеге Тәртип кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә мөлкәт ярдәме күрсәтү максатларында түләүле озак сроклы нигездә (шул исәптән ташламалы шартларда) ия булу яисә файдалану өчен билгеләнгән, өченче затлар хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәт, шул исәптән җир кишәрлекләре (шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелешен алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш), исемлеген (алга таба – Исемлек) формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару ысулын билгели.

**1.2.** Исемлекне формалаштыру Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 2. Исемлекне формалаштыру тәртибе.

**2.1.** Әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән, өченче затларның башка хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан тыш) ирекле, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы казнасы мөлкәте булып торган муниципаль мөлкәт Исемлеге төзелә.

**2.2.** Кече һәм урта эшкуарлык субъекты тарафыннан арендалана торган мөлкәтне Исемлеккә керткәндә, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен арендалана торган мөлкәтне алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашыру тәртибенә карата 2008 елның 22 июлендәге «Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге һәм арендалана торган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан бирелгән күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 159-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-159-ФЗ номерлы федераль закон) нигезләмәләре турында, шулай ук Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалаучы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен ташламалар турында мәгълүмат күрсәтелгән тиешле тәкъдим юллау юлы белән арендалаучыдан милекне Исемлеккә кертү өчен язмача рөхсәт кәгазе алырга кирәк.

**2.3.** Арендага бирелгән мөлкәтне исемлектән төшереп калдыру турындагы карар, милекне исемлектән төшереп калдыру аның юкка чыгуы яисә бетүе, шулай ук арендалаучының 159-ФЗ номерлы Закон нигезендә мөлкәтне сатып алу нәтиҗәсендә мөлкәтнең гамәлдә булуы тукталу кебек хәлләргә бәйле очраклардан тыш очракларда арендаторның язма ризалыгы булганда кабул ителә.

**2.4.** Исемлеккә түбәндәге критерийларга туры килә торган мөлкәт турында белешмәләр кертелә:

1) өченче затлар хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) ирекле мөлкәт;

2) федераль законнар белән вакытлыча ия булуга һәм (яки) файдалануга, шул исәптән арендага бирүне тыю билгеләнмәгән мөлкәткә карата;

3) дини билгеләнештә булмаган милек объекты;

4) җирле үзидарә органының норматив хокукый акты белән капиталь төзелеш объектларын арендага бирү реконструкцияләүне, капиталь ремонт үткәрүне, төзелешне тәмамлауны таләп итү җайга салынган очрактан тыш капиталь ремонт яисә реконструкция үткәрүне таләп итмәгән, төгәлләнмәгән төзелеш объекты булып тормаган мөлкәт;

5) агымдагы елда һәм аннан соңгы чорда 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кабул ителгән муниципаль милекне хосусыйлаштыру Планына, шулай ук ачык-хокукый берәмлектәге социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга озак сроклы нигездә файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән мөлкәт исемлегенә кертелмәгән мөлкәт; милеккә карата өченче затка бирү турында милекче тарафыннан башка үтәлергә тиешле карар кабул ителмәгән мөлкәт;

6) авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип танылмаган мөлкәт;

7) торак фондка керми һәм торак фонды объекты тоташтырылган инженер-техник тәэмин итү челтәре объекты булып тормаган мөлкәт;

8) шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнмәгән җир кишәрлеге;

9) кече һәм урта эшмәкәрлеккә арендага бирелгән җир кишәрлекләреннән тыш, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 8 пунктының 1-10, 13-15, 18 һәм 19 пунктчаларында каралган җир кишәрлекләренә кермәгән җир кишәрлеге;

10) муниципаль унитар предприятиегә хуҗалык алып бару яисә оператив идарә хокукында беркетелгән мөлкәткә карата, хуҗалык алып бару яки оператив идарә хокукында ия булган муниципаль учреждениегә оператив идарә хокукында, баланс тотучының әлеге мөлкәтне исемлеккә кертү турындагы тәкъдиме, шулай ук тиешле мөлкәт белән алыш-бирешне килештерергә вәкаләтле Арча муниципаль районы Башкарма комитетының язма ризалыгы булган мөлкәткә карата;

11) файдалану барышында үзенең кулланылыш үзенчәлекләрен югалтмаган әйберләргә (кулланыла торган әйберләргә), аз кыйммәтле күчемле мөлкәткә, хезмәт итү срогы биш елдан ким булган яки аны Россия Федерациясе законнары нигезендә биш һәм аннан күбрәк елга арендага бирү рөхсәт ителми торган мөлкәткә кермәгән, шулай ук бүленми торган әйбернең бер өлеше булып тормаган мөлкәт;

12) аренда шартнамәсен яисә башка гражданлык-хокукый шартнамәсе төзергә мөмкинлек бирүче шәхси-билгеле үзлекләргә ия күчемле мөлкәт;

13) кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты тарафыннан өч елдан да ким булмаган милеккә карата арендалаучы вәкаләтле органның әлеге Тәртипнең 2.4 пунктында күрсәтелгән тәкъдименә җавап итеп исемлеккә кертү өчен каршылыклар җибәрелмәгән мөлкәткә карата;

14) милеккә карата аренда килешүе яки гамәлдә булу срогы кимендә биш ел тәшкил иткән башкаия булу яисә файдалану килешүе төзелгән булса.

**2.5.** Исемлеккә әлеге Тәртипнең 2.4 пунктында күрсәтелгән критерийларга туры килә торган түбәндәге мөлкәт кертелә:

1) күчемсез милек: техник торышы, икътисадый характеристикалары һәм мораль тузуы исәпкә алынган файдалануга яраклы, хезмәт итү срогы Исемлеккә кертү датасына биш елдан артык булган җиһазлар, машиналар, механизмнар, җайланмалар, инвентарь, инструментлар;

2) инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтырылган һәм транспорт инфраструктурасы объектларына үтү мөмкинлеге булган күчемсез мөлкәт объектлары;

3) торак пункт чикләрендә урнашкан административ, сәүдә яки офис максатлары өчен файдалану планлаштырыла торган күчемсез милек объектлары;

4) баланс тотучының күрсәтелгән мөлкәтне Исемлеккә кертү турындагы тәкъдиме белән хуҗалык алып бару яисә оператив идарә хокукында ия булган муниципаль учреждениегә оператив идарә хокукында беркетелгән, шулай ук әлеге мөлкәт белән алыш-бирешне килештерергә вәкаләтле Арча муниципаль районы Башкарма комитетының мөлкәтне Исемлеккә кертүгә язма ризалыгы булган муниципаль унитар предприятиегә хуҗалык алып бару яисә оператив идарә хокукында беркетелгән мөлкәт;

5) Россия Федерациясе Җир кодексының 11⁹ статьясы нигезендә үлчәмнәре билгеләнгән чик үлчәмнәренә туры килә торган, шулай ук авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләре, шул исәптән инвестиция эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре.

2.6. Муниципаль унитар предприятиегә хуҗалык алып бару яки оператив идарә хокукында беркетелгән муниципаль мөлкәт әлеге предприятие яки учреждение тәкъдиме буенча һәм тиешле милек белән алыш-бирешне килештерергә вәкаләтле Арча муниципаль районы Башкарма комитеты ризалыгы белән муниципаль учреждениегә оператив идарә хокукында әлеге предприятие яки учреждение тәкъдиме буенча Исемлеккә кертелә.

2.7.Мөлкәтне Исемлектән төшерү түбәндәге очракларда башкарыла:

1) милеккә карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә аны муниципаль ихтыяҗлар өчен куллану турында карар кабул ителгәндә. Мөлкәтне исемлектән төшереп калдыру турындагы карарда мөлкәттән файдалану юнәлеше һәм тиешле карар реквизитлары күрсәтелә;

2) милеккә муниципаль милек хокукы суд карары буенча яисә законда билгеләнгән башка тәртиптә туктатылганда;

3) юкка чыгарылуы яисә бетерелүе нәтиҗәсендә мөлкәт гамәлдән чыгарылганда;

4) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә физик яки мораль тузуы, авария хәленә җитүе нәтиҗәсендә файдалану өчен яраксыз дип танылганда;

5) күләм һәм сыйфат характеристикалары үзгәрү нәтиҗәсендә мөлкәтнең үз билгеләнеше буенча файдалану өчен яраксызга әйләнүе;

6) мөлкәтне билгеләнгән тәртиптә федераль милеккә, Татарстан Республикасы милкенә, Татарстан Республикасының Арча муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре милкенә тапшыру;

7) гамәлдәге законнар нигезендә аукционнар үткәрү нәтиҗәләре буенча аренда килешүләре төзелмәгәндә, муниципаль милекне арендалау шартнамәсе төзү хокукына өч тапкыр аукционнар (конкурслар) уздыру. Әлеге мөлкәткә карата аны алга таба файдалану буенча идарә карары кабул ителә.

2.8. Мөлкәт исемлеге Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

## 3. Исемлекне алып бару тәртибе.

**3.1.** Исемлекне алып бару Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан кәгазьдә һәм электрон формада башкарыла.

**3.2.** Исемлек түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган реестрдан гыйбарәт:

- тәртип буенча номер;
- мөлкәтнең реестр номеры;
- муниципаль күчемсез мөлкәтнең урнашу урыны;
- күчемсез милек объектының төре;
- мөлкәтнең идентификацион мәгълүматлары (кадастр номеры һ. б.);
- мөлкәтнең характеристикасы (мәйданы, катлылыгы, озынлыгы һ. б.);
- муниципаль мөлкәт исеме;
- мөлкәтнең хокук иясе;

– мөлкәткә карата чикләүләр (йөкләүләр) турында мәгълүмат.

## 4. Исемлекне бастырып чыгару тәртибе.

**4.1.** Исемлек һәм аңа кертелә торган үзгәрешләр Татарстан Республикасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Хокукый мәгълүматлар рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы һәм Арча муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru адресы буенча мәҗбүри бастырып чыгарылырга тиеш.